**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕКТАУ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422701 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский
район,с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д. 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**30 апрель 2025 ел** **№ 450**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендәге 346 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге җирле узидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле узидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 нче елның 28 нче мартындагы 182 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Биектау авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 нче елның 28 нче апрелендә 346 нчы номерлы Биектау авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2018 нче елның 28 нче декабрендәге

468 нче номерлы, 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 425 нче номерлы, 2020 нче елның 15 нче октябрендәге 12 нче номерлы, 2022 нче елның 13 нче октябрендәге 233 нче номерлы, 2022 нче елның 24 нче ноябрендәге 245 нче номерлы, 2024 нче елның 28 нче июнендәге 372 номерлы, 2024 нче елның 17 декабрендәге 415 нче номерлы, 2025 нче елның 30 гыйнварыннан 431 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә):

- 1 нче пунктның 3 нче абзацында «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

- 2 нче пунктның 2.1 нче подпунктының 3 нче абзацында «17,4» саннарын «20,43» саннарына алмаштырырга;

- 2 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Башлыгын акчалата бүләкләү күләмнәре» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 9 төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы | 28 632 |

- 6 нчы кушымтаның «Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләме» 1 нче пунктында «41 процент» сүзен «58 процент» сүзләре белән алыштырырга;

- «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы фондын формалаштыру тәртибе» 11 нче кушымтаның 1 нче пунктының 6 нчы пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карар 2025 нче елның 1 нче маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А.Хабибуллин